**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**20 нче апрель 2021 ел** **№ 75**

**Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданының хисап нормасы һәм торак урын мәйданын бирү нормасы турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьялары нигезендә, дәүләт торак программаларын гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын, шуннан чыгып Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында гражданнарның торак урынның гомуми мәйданы белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе билгеләнә, гаиләнең бер әгъзасына торак урынның гомуми мәйданы 18 кв. метрдан артмаган күләмендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннар белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданы бирү нормасын бер гражданга торак урынның гомуми мәйданын 18 кв. метр күләмендә билгеләргә.

3. Торак урынның гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 13 октябрендәге 172 номерлы «Социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак биргәндә һәм исәпкә куйганда торак мәйданының нормалары турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының социаль сәясәт, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, спорт һәм яшьләр сәясәте буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин